ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СОСНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОСНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» декабрь 2022 ел № 15

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына юл сервисы объектларын тоташтыру буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен һәм исемлеген билгеләү турында

2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 һәм 22 статьялары нигезендә «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына юл сервисы объектларын тоташтыру буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен һәм исемлеген әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (baltasi.tatarstan.ru) «Поселения» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Сосна авыл җирлеге башлыгы Ф.С.Габдрахманов

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районынын Сосна авыл жирлеге башкарма комитетынын 20.12.2022 елгы №15 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе һәм исемлеге

| N п/п | Хезмәтнең исеме | III-V категорияле юл |
|---|---|---|
| | | Бәясе, сум |
| 1. | Җәмәгать туклануы пунктын (кафе, ресторан һ.б.), кибетне кушу | 35 803,68 |
| 2. | Техник хезмәт күрсәтү станциясен (шиномонтаж) кушу | 30 921,36 |
| 3. | Техник хезмәт күрсәтү станциясен кушу (ремонт, юу) | 39 058,56 |
| 4. | Базарны кушу (оешкан сәүдә нокталары) | 39 058,56 |
| 5. | Транспорт чараларын туктату урыннарын һәм тукталыш урыннарын кушу (юл сервисы объектларында) | 26 039,04 |
| 6. | Автомобильгә ягулык салу станциясенең кушылуы | 47 195,76 |
| 7. | Юл сервисы комплексын кушу | 47 195,76 |
| 8. | Автомобильгә ягулык салу станциясе белән юл сервисы комплексын кушу | 56 960,4 |
| 9. | Сәүдә комплексы кушылу | 47 195,76 |
| 10. | Йөк автотранспортына хезмәт күрсәтүче биналар һәм корылмалар (йөк автомобильләре станцияләре, терминаллар, түләүле автостоянкалар һ.б.) кушылу | 52 078,08 |